**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от 20.06.2022** **№ 610**

**2022 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күрсәткечләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 ст., 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законы һәм күрсәтелгән Законга кушымтада бәян ителгән Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләмнәрен билгеләү методикасы нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының 2022 елга бәясе нормативы һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 2020 елның 29 июнендәге 351/пр номерлы боерыгына таянып, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елга гражданнарны тану турында карар кабул итү өчен чик күрсәткечләр билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләме:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 1 024 896 сум;

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен - 2 049 792,12 сум;

1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен - 3 074 688,18 сум;

1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен - 4 099 584,24 сум;

1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен - 5 124 480,3 сум;

1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен - 4 420 483,2 сум;

1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен - 6 149 376,36 сум;

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 34 441,33 сум;

1.2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен - 34 441,33 сум;

1.2.3. Өч кешедән торган гаилә өчен - 34 441,33 сум.

2. Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты Төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлегенең торакны исәпкә алу һәм бүлү секторына әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән күрсәткечләрне гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар сыйфатында исәпкә куйганда кулланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф.Хисамутдинов